*Татарстан Республикасы Нурлат  муниципаль районы*
*муниципаль автоном белем бирү учреждениесе*
*“М.Е.Сергеев исемендәге  Нурлат гимназиясе”*

# *Мин-укытучы*

темасына эссе

*Әзерләде: беренче квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Шәйхетдинова Гөлия Наил кызы*

*Нурлат, 2016*

*Хезмәтемнең сукмагыннан*

*Барган чакта тиз-тиз атлап.*

*Гаделлек һәм таләпчәнлек*

*Йөртә мине һаман саклап.*

*Җиңел түгел барыр юлдан,*

*Тиз-тиз генә алга атлап.*

*Зилзиләләр көтеп тора*

*Борылышта мине кайчак.*

*Көтеп тора борылышта*

*Авырлык та, киртәләр дә,*

*Шатлыгы да бу тормышта.*

*Нәтиҗәмне күрим диеп,*

*Алга таба атлыйм һәрчак.*

**Укытучы** ... Күпме мәгънә, күпме аң, балаларга һәм кешелеккә булган күпме мәхәббәт хисләре тупланган бу сүздә... Чыннан да, гади сүз түгел бу... Тормышны яхшылыкка үзгәртүче, дөньяга матурлык өстәүче, кечкенә сабыйлардан зур Шәхес үстерүче, тәрбияләүче, олы тормышка юл күрсәтүче, озатып калучы бөек җан ул – Укытучы.

Һәр кеше дә бу дөньяда укытучы була ала микән? Минемчә, юктыр. Чөнки әлеге бөек һөнәргә сабыр холыклы, тирән белемле, ә иң мөһиме, бала җанлы һәм киң күңелле кешеләр генә лаектыр.

Укытучы һөнәрен төрле кеше төрлечә аңлый. Минемчә, укытучы, иң беренче чиратта, бала күңелен аңлый белүче изге йөрәкле тәрбияче, ата-анага төпле киңәш бирүче педагог булса, икенчедән, ул мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле ирекле шәхес формалаштыручы остаз да булырга тиеш.

Һәр укытучының үз язмышын мәктәп белән бәйләве дә төрлечә. Берәүләр балачактан ук үзләрен бу һөнәргә багышлаячакларын тоемлыйлар һәм шуңа

омтылалар, әзерләнәләр. Икенчеләр исә балага белем бирү, аны олы тормыш юлына әзерләү кебек изге эшкә очраклы рәвештә кереп китәләр. Мин үземне шуларның беренчесенә кертер идем.

Укытучылар нәселеннән булгангадыр, кечкенәдән үк минем хыялым укытучы булу иде. Балачакта курчакларга билге куеп уйнасам, мәктәпне тәмамлаганда, туган телемә булган мәхәббәтем Алабуга дәүләт педагогика университетытының татар филологиясе факультетына алып килде.

Ә 5 елдан инде мин югары белемле филолог, татар теле һәм әдәбияты укытучысы дипломына ия булган яшь укытучы идем. Дөресен әйтим, шулвакытта кая барырга, укыган белгечлек буенча китәргәме, әллә инде башка юнәлешне сайларгамы дигән сораулар алдында тукталып калдым. ”Барма мәктәпкә, бер кереп китсәң, чыга алмыйсың, “Яңа гасыр балалары” белән эшләве бик кыен булыр”, - дип әйтүчеләр дә булды. Шулай да мин, үз хыялларымны алга куеп, университетта белем биргән, тормыш дәрьясының югары баскычларына күтәргән остазларымның киңәшләрен тыңлап, мәктәп дигән олы дөньяга юл тоттым.

Остазларымның: “Бала күңеле - бәллүр ваза. Әгәр дә аны ватасың икән, ничек кенә кире ябыштырырга теләсәң дә, барып чыкмас, сак булыгыз!” , - дигән киңәшләре мине төрле сораулар алдында калдырды. Бала күңеленә юлны кайдан табарга? Ничек дөрес эшләргә, нинди метод һәм алымнар кулланырга? Рус телле укучылар белән ничек эшләргә? Җиңел булды димим хезмәтемнең тәүге баскычларын. Беренче сентябрь, үземнән 5-6 яшь кенә кече укучылар алдына дәреслек тотып кереп басулар, калтыранган тавыш белән тема аңлатулар бүгенгедәй хәтеремдә... Хәзер исә мин укытучы исемен горур итеп күтәреп йөрер дәрәҗәгә ирешкән хезмәт иясе! менә шул мине куркытырга теләгән “яңа гасыр балалары” белән эшләргә теләгән, бүгенге катлаулы тормышта аларга үз юлларын табарга, белемле, теләкләренә ирешә алырдай, намуслы, рухый яктан нык, тәрбияле, мөстәкыйль фикер йөртә белүче, милләтен һәм мәдәниятен яратырдай шәхес тәрбияләргә теләгән гади бер зат.

Мин – татар теле укытучысы. Дәрескә керер алдыннан укучыларымның һәрберсен күз алдымнан үткәрәм, аларның күңел дөньясын ачарга, ышанычларын акларга тырышам. Кәефем нинди булуга карамастан, алар янына ачык күңел белән керәм,

чөнки баланың сизгер йөрәген алдый алмыйсың. Аның күңеленә кешелеклелек, игелеклелек орлыклары салырга җыенасың икән, иң беренче чиратта үзең үрнәк булырга тиешсең.

Элек-электән укытучы хезмәте - гаять катлаулы һәм җаваплы хезмәт булып саналган. Без билгеле бер дәрәҗәдә яңача фикерләүгә игътибар бирелгән, фән-техника өлкәсендә, хезмәттә әледән-әле яңа ачышлар ясала торган заманда яшибез. Үзгәрешләр уку-укыту процессын да урап узмый.

Хәзерге вакытта мин 6нчы сыйныфларның сыйныф җитәкчесе. Мин алар белән төрле конкурсларда, кичәләрдә катнашам. Сыйныф җитәкчесе булгач, турнирларда йөгерәсең дә, командир да буласың, җырлыйсың да, биисең дә, сәхнәдә артист та буласың, кирәк чакта режиссер да буласың икән. Шул чакларда укытучы һөнәре белән беррәттән тагын берничә һөнәргә ия булуыңны аңлыйсың. Рус сыйныфы булуга карамастан, без күбрәк татарча аралашабыз.Сыйныф сәгатьләрен дә татар телендә уздырырга тырышам. Әти-әниләр белән даими элемтәдә торабыз. Алар татар телен өйрәнүдә булган кыенлыклар белән уртаклашалар, бер-беребзгә ярдәмләшеп яшибез.

Мин –бәхетле, әле кичә генә тормыш сукмагыннан атлап барган тәҗрибәсез укытучы кыз идем, борылып карасам, 17 ел вакыт үтеп киткән. “Очасым” килә, белем үрләренең иң биек ноктасына күтәреләсем, кешеләргә файда китереп яшисем килә. Яшәгән саен яшьнисем килә!

*Бу тормышта минем адымым нык,*
*Укытучы-минем һөнәрем!*
*Бар көчемне, талантымны биреп,*
*Балалар дип уза көннәрем!*